**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зеленая Роща авыл җирлегенең Спиридоновка торак пунктында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2023 елның 18 ноябре № 2

**2023 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Зеленая Роща авыл җирлегенең Спиридоновка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Зеленая Роща авыл җирлеге Спиридоновка торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Зеленая Роща авыл җирлеге Спиридоновка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

1) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү, җирлек территориясен төзекләндерүне күрсәтелгәнкКагыйдәләргә ярашлы оештыру, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру:
- Спиридоновка авылында урам яктыртуына техник хезмәт күрсәтү,
- җәйге чорда Спиридоновка авылында үлән чабу;

2) торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:
- Спиридоновка авылында эчә торган су водоводын ремонтлау һәм төзү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Спиридоновка авылы, Совет урамы, 32 нче йорт Спиридоновка авыл клубы бинасы адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Зеленая Роща авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.А.Потапов